**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районының**
**«Мордва Афонькәсе авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге составына керүче Мордва Афонькәсе авылы торак пунктында

**12 октябрь 2023 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлегенең торак пунктларында гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2024 елда Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлегенең Мордва Афонькәсе авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 600 сум күләмендә үзара салым кертергә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасында һәм Донецк халык республикасында махсус операциядә булган затлардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрергә:

- Мордва Афонькәсе авылы торак пунктында урам утларын монтажлау, урнаштыру, ремонтлау, карап тоту һәм хезмәт күрсәтү, кулланылган электр энергиясе өчен түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- Җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерүгә, карап тотуга, хезмәт күрсәтүгә (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәтләр өчен түләү, запас частьләр сатып алу), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнары;
- Мордва Афонькәсе авылында Цаплин урамы буенча авыл эчендәге юлны чикләү.
- Су насосларын сатып алу (ремонтлау), суүткәргеч челтәрләрен ремонтлау.
- Мордва Афонькәсе авылындагы чишмәне төзекләндерү (вывесканы яңарту, буяу), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу.

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
ТР Чирмешән муниципаль районы
Мордва Афонькәсе авыл җирлеге башлыгы А.И.Митяев